وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلا تَفَرَّقُواْ

Ий мөәминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

Дин вә Мәгыйшәт

№8 (151). 24 август 2012 / 6-шәүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

Коръән – Исламның иң төп чыганагы ▷2◁

Әдәбият тарихында азатлык өчен көрәш сәхифәләре ▷3◁

Иремнең икенче хатыны барлыгын белдем... ▷4◁

ЯКЫНЛАШЫП КИЛҮЧЕ РЕСПУБЛИКА ҺӘМ ШӘҺӘР КӨНЕ БЕЛӘН!

Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү!

Хөрмәтле татарстанлылар! Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барыгызны да 30 август - Республика һәм шәһәр көне белән тәбрик итәм!

Республикабызның яңа чор тарихы ике дистә елдан артык вакытны үз эченә ала. Бу рухи һәм мәдәни яңарыш елларында, без ныклы ышаныч казана алдык, һәм хәзер кыю рәвештә уңышка ирешүләребез белән горурлана алабыз.

Бүген безнең күнелләребез шатлык белән тулы: татар халкы бердәмлеккә омтылып һәм үз диненең мирасын өйрәнеп-барлап, хәзерге чынбарлыкның катлаулы күренешләрен җиңеп чыгарга өмет-ышаныч бирүче Ислам тәгълиматларына таянып яши ала. Исламның әхлакый кыйммәтләре безгә дуслык-татулык һәм динара, милләтара толерантлык мохитен барлыкка китерергә ярдәм итте. Иншә Аллаһ, уңышларыбыз киләчәк буыннарга да горурланырлык бер үрнәк күрсәткеч булып барып ирешер, алга таба да республикабызның алгарышына ярдәм итәр.

Аллаһы Тәгалә татарстанлыларга авырлыкларны җиңеп чыгуда рухи ныклык, бердәмлек, сабырлык әйләсен, дини-милли байлыгыбызны саклауда һәм үстерүдә ярдәменнән ташламаса иде.

Хак Тәгаләнең сезгә чиксез сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте бу дөньяда да һәм ахирәттә дә булса иде!

Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ

Сез Исламга әзерме?

БЕЗ кешелек тарихының үзгә чорында яшибез. Безгә күптән түгел генә тормышыбызга үтеп кергән, кешенең эшчәнлеген һәм көнкүрешен шактый җиңеләйтә торган искиткеч яхшы технологияләр тәкъдим ителә. Әмма хәзергедәй зирәк һәм киң белемле буынга авыр сынаулар да күрергә туры килә. Байлар һәм фәкыйрьләр арасындагы градация (бер нәрсәдән икенчесенә күчкәндәге эзлеклелек) көтмәгәндә генә булып куйды. Медицина һәм авыл хуҗалыгы тармагындагы алгарышка да карамастан, дөньяда ачлыктан интегүчеләр, эпидемияләрдән җәфаланучылар күпкә арты, ә техноген һәлакәтләр шундый җимергеч көч хасил итә башлады ки, әйтерсең лә безнең Армагеддонга яки Апокалипсиска килеп җитүебез беренче генә булмады. Җәмгыятебезне наркотиклар, алкоголь һәм тәмәке басып алды. Без кешелек дәрәҗәсен төшерә торган теләкләр колына әверелдек. Җинаятьчелек белән көрәш нәтиҗәләр бирми диярлек. Халык хәтта яши торган урынында да үзен куркынычсыз итеп хис итми башлады. Менә шуннан чыгып без үзебезне цивилизацияле җәмгыятьтә яшибез дип йөрибез дә инде.

Дөньяда булган барлык тискәре күренешләргә дә каршы тору чарасы булып Ислам тора. Ул алкоголь һәм наркотиклар куллануның зыянын фаш итүче бердәнбер дин (мәгънәсе): "Әй, мөселманнар! Исерткеч эчү, азгын уеннар уйнау, табынгыч сыннарга баш ору, ырымланган уклар белән шобага салу шайтан гамәлләредер, шакшылыктыр, мондыйлардан ерак торыгыз: котылырсыз (бәхеткә ирешерсез). Исерткеч һәм азгын уеннар белән шайтан арагызда үч орлыкларын, дошманлык чәчә; Аллаһны искә төшерүдән вә намаздан биздерергә тели. Сез бу эшләрдән ваз кичә алырсызмы икән?" ("әл-Маидә (Табын)" сүрәсе, 90-91 нче аятләр).

Дөнья икътисады безнең көннәрдә бик тиз алмашынып тора ки, аның үзгәрешләре артыннан җитү беркемнең дә хәленнән килми. Башлыча, барлык әлеге күренешләргә (үсеп килүче илләргә буталчыклык (хаос) китереп чыгару өчен, аларның гаять зур акчаларын алып, табигать вә кеше ресурсларын үз карашларына төбәү) кредитлар буенча ставкалар, Бөтендөнья Банкы һәм Халыкара валюта фонды тарафыннан кулланыла торган система йогынты ясый. Коръәндә әйтелгән (мәгънәсе): "Риба (әҗәткә биреп торган акчадан-малдан арттырып алынган хәрам керем) ашаганнар исә шайтан зәхмәте суккан тилеләр кебек, каберләреннән кубар. Алар: "Сәүдә итү дә риба кебек бит", - дигәннәре өчен шундый хәлдә калырлар. Хәлбуки, Аллаһ сәүдәне (алыш-бирешне) хәләл итте, рибаны хәрам кылды. Әгәр дә кемдер Аллаһтан (риба алмаска) үгет килгәч, рибадан баш

тартса, үз файдасына булыр. Аның эше Аллаһ хөкемендә булыр. Кем кабаттан (бу аять иңгәннән соң) риба ала калса, андыйлар җәһәннәм әһелләре булыр һәм алар шунда дәвамлы калыр" ("Бәкара (Сыер) сүрәсе", 275 нче аять).

Шул ук сүрәдә: "Иман китергән кешеләр! Мөселман икәнсез, Аллаһның нәфрәтеннән куркыгыз, алынмаган рибаларыгызны алмагыз" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 278 нче аять), - диелә. Шунда ук ике як сәүдә килешүендә үзләрен ничек тотарга тиеш икәнлеге китерелә: "Әгәр (сезгә бурычлы кеше әҗәтен кайтарырга) кыен хәлдә калган булса, бурычын түләр өчен аңа уңай вакыт бирегез" ("Бәкара (Сыер) сүрәсе", 280 нче аять).

Теләсә кайсы зур шәһәрдә, кирәк ул Америкада яисә Россиядә булсын, бәхетсезлеккә юлыгу сәбәпле сыеныр урыны булмаганнарны бик тиз табарга мөмкин. Ислам дине, акчасы булганнарга байлыкларыннан бер өлешне фәкыйрьләргә бирүне таләп итеп, мал-мөлкәт җыюны тыя. Бу күрсәтмә Коръәндә берничә мәртәбә кабатлана: "(Сәдака) үзләрен Аллаһ юлына багышлаганнарга (фәкыйрьләргә, галимнәргә) бирелергә тиеш. Чөнки алар Җир йөзе буйлап йөри алмый. Аларның хәлен белмәгән наданнар, аларның тыйнак һәм итагатьле булганнарына карап, хәер сорашмаган-

(Ахыры 2 нче биттә.)

ЯҢАЛЫКЛАР

ТАТАРСТАНДАГЫ ДИНИ УКУ ЙОРТЛАРЫ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ КИҢӘШМӘСЕ УЗДЫРЫЛА

Бүген ТР мөселманнары Дания нәзарәтендә сәгать унда (10.00) "Татарстанда дини мәгариф: дини уку йортлары эшчәнлеге, методик тәэмин ителеш һәм яңа уку елына әзерлек" дип аталган киңәшмә уздырыла. Көн тәртибе буенча дини уку йортларын яңа уку елына әзерләү һәм дини белем бирү сыйфатын үстерүгә кагылышлы мәсьәләләр каралачак. Киңәшмәдә мөфти вазифаларын башкаручы Габдулла хәзрәт Әдһәмов, Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе ректоры Наил хәзрәт Яруллин, Казан ислам көллияте директоры Мансур хәзрәт Җәләлетдин, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин һ. б. уку йортлары җитәкчеләре катнаша. Әлеге чарада Габдулла хәзрәт Әдһәмовның "Гакыйдә" китабын тәкъдим итү булачак.

ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ ҮТТЕ

Утырышта Югары Ослан муниципаль районында дини экстремизмга каршы көрәш һәм профилактик чаралар күрү буенча төп мәсьәләләр каралды.

Районның имам-мөхтәсибе Гали хәзрәт Җиһаншин үз чыгышында ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм район мөхтәсибәте әлеге юнәлештә актив эшчәнлек алып баруын билгеләп үтте. Ул шулай ук халык арасында хәзрәтләрнең ролен үстерү киләклеген дә ассызыклады.

АРЧА РАЙОНЫНДА ЯҢА МӘЧЕТ АЧЫЛАЧАК

25 август көнне Арча районының Алан авылында яңа мәчет ачылачак. Мәчет төзелешенә ике еллап вакыт сарыф ителгән. Бу - Арча районында җитмеш алтынчы мәчет булачак. Яңа мәчеттә имам-хатыйб вазифасын Фәнис хәзрәт башкарыр дип көтелә. Мәчет ачылышында Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Арча муниципаль районы башлыгы Алмас Нәзиров, район имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗев һ. б. кунаклар катнашыр дип көтелә.

ЧҮПРӘЛЕ РАЙОНЫНДА ДИНИ ҖЫЕН - МУНЧӘЛИ УКУЛАРЫ УЗАЧАК

25 август көнне Чүпрәле районының Мунчәли авылында бишенче тапкыр Авыл бәйрәме үткәреләчәк. Бәйрәм кысаларында мәчетнең 15 еллыгына багышлап дини җыен - Мунчәли укуларын оештыру планлаштырыла. Чарада шулай ук татар драматургы, ТР Дәүләт Советы депутаты, мәрхүм Туфан Габдулла улы Миңнуллинны искә алу булачак, аның истәлегенә мемориаль такта ачылачак. Бу хакта оештыру комитеты рәисе, Чүпрәле районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илмир Измайлов хәбәр итә.

Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды

2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

КОРЪӘН – ИСЛАМНЫҢ ИҢ ТӨП ЧЫГАНАГЫ

Коръән иңү. Коръәннең төзелеше

Коръәнне язма рәвештә теркәү. Изге Коръән Мөхәммәд пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) өлешләп индерелгән. Чираттагы Илаһи Сүзне кабул иткәч, ул аны шунда ук язып куярга кушкан. Хәтта иң авыр минутларда да, Мәккәдән Мәдинәгә күчкән вакытта да, хәрби чыгышлар вакытында да, аның янында индерелгән аятьләрнең текстын теркәргә әзер торучы, язу эшләрен башкаручы берәр кеше торган.

Мәккәдә Коръән текстларын иң беренче Абдулла бине Саад язып барган. Мәдинәдә бу мактаулы эш Убай бине Каабка йөкләнгән. Ачылышларны язып баручылар арасында Әбу Бәкер, Гомәр бине әл-Хәттаб, Госман бине Гаффан, Али бине Әбу Талиб, Зөбәер бине әл-Аүвам, Хәнзилә бине әр-Раби, Шураһбил бине Хәсәнә, Габдулла бине Рәваха һәм башкалар булган. Коръәнне Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сүзләреннән аның кырыкка якын сәхабәсе язып барган.

Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вакытында аятьләр хөрмә агачы яфракларына, яссы ташларга, тире кисәкләренә, дөяләрнең калак сөякләренә язылып барылганнар. Язу өчен караны корымнан ясаганнар. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) индерелгән аятьләрне кая, кайсы сүрәгә урнаштырырга кирәк икәнлеген аңлаткан. Аллаһның Сүзләрен теркәп куйгач, язып баручы аны Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) укып күрсәткән, хаталар җибәрелгән очракта, аның җитәкчелегендә алар төзәтелгәннәр.

Коръәннең тулы сакланышын тәэмин итәр өчен Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сәхабәләрен Коръәнне ятларга өндәгән. Күп кенә мөселманнар бар Коръәнне яттан белгәннәр.

Коръән тулысынча Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзе исән вакытта ук язмага күчерелеп беткән булган. Күп кенә хәдисләр шул турыда сөйли. Мәсәлән, Мөслимнән китерелгән хәдистә: "Коръән белән сәяхәт кылмагыз. Дошманнар кулына эләгүе бар", - диелгән. Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Әмир бине Хәмзәгә җибәрелгән билгеле юлламасында: "Дини чистарыну үтмәгән бер генә кеше дә Коръәнгә кагылмасын", - диелә (Мәлик, Нәсаи). Болар, һәм шуңа охшаш башка хәлләр, сәхабәләрдә Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вакытында ук язмача теркәлгән Коръәннең күп нөсхәләрдә булуын дәлилли. Шул рәвешчә Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) заманында Коръән ике мәгънәсендә дә сакланып калган: кешеләрнең күңелләрендә дә, язма рәвештә дә.

Тик әле ул бер китап буларак җыелмаган була. Бу эшчәнлек күптөрле сәбәпләр аркасында мөмкин булмаган.

Беренчедән, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) чорында, Коръәнне төрле аерым битләргә генә язып барган вакытта, аны бер җыентыкка туплауның - Коръәнне язма төргәкләргә теркәргә кушкан Әбу Бәкер хәлифә вакытындагы кебек, яки Коръәнне бер китапка туплап, аның төгәл күчерелмәләрен эшләргә кушкан хәлифә Госман хакимлеге вакытындагы кебек, - ул кадәр зарурлыгы да булмаган. Ул вакытларда мөселман җәмгыяте иң югары күтәрелеш чорын кичергән. Коръәнне яттан укучылар күп булган. Ул чор гарәп халкында, язма текстларга нигезләнүгә караганда, яттан сөйләү сәнгатенә зур өстенлек бирелгән.

Икенчедән, Коръән тулаем индерелмәгән, Хакыйкать индерелү егерме өч ел буе дәвам иткән.

Өченчедән, Аллаһы Тәгалә теләсә, Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) элек индерелгән аять яки аятьләрне инкарь итәрлек яңа фикер, ачыш индерелү мөмкинлеге алдында да торган, чөнки, индерелгән соңгы аять белән Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вафаты арасында бары тугыз гына көн һ. б.

Коръәнне бер җыентыкка туплау. Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вафатыннан соң, Коръәнне белүчеләрнең саны кими һәм аның текстын өлешчә югалту ачык күзаллана. Гомәр бине әл-Хәттаб хәлифәне - ягъни Әбу Бәкерне барлык Коръән белгечләре дә хуплаган киңәшкә - бердәм җыентык төзү кирәклегенә күндерә. Гомәрнең тәкъдимен, изге башлангычын хуплап, хәлифә Зәед бине Сабитка, Мәдинәдә яшәүче барлык сәхабәләрдән Коръән язмаларын җыеп алырга, аять һәм сүрәләрне Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзе укыган эзлеклелектә урнаштыру һәм дә ул җыентыкны башка галимнәр фикере белән дә килештерү бурычын йөкли. Бу эшчәнлек елга якын дәвам итә, аннан соң килешенгән, фикер уртаклыгы табылган бу җыентык Әбу Бәкергә тәкъдим ителә. Хәлифәнең вафатыннан соң Коръән тексты Гомәр хәлифәгә, ә аннан соң, васыяте буенча, аның кызына, Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хатыны, бар мөәминнәрнең анасы буларак саналган Хафсә бине Гомәргә күчә.

Гаптрәүф НУРИЕВ,
филология фәннәре докторы;
Нияз САБИРҖАНОВ

Сез Исламга әзерме?

(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

нарына күрә, бу адәмнәрне бай диеп уйлыйлар. Син аларны (үзләренә генә хас) галәмәтләреннән танырсың. Алар (кыен хәлдә булсалар да күзгә керә-керә) хәер сорамый. Сезнең (Хак юлында) күпме мал сарыф иткәнегезне, шик юк ки, Аллаһ, хакыйкатән, белеп тора" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 273 нче аять). "Мөәминнәр, игелек кылганнар, намазны дөрес укыганнар, зәкятен биргәннәр Раббының хозурында әҗерләрен табар. Аларга һичбер куркыныч янамас, аларга хәсрәт тә килмәячәк" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 277 нче аять).

Зәкят - ислам диненең төп нигез булып торган кагыйдәләреннән санала. Ул кешелек җәмгыятендә байлыкны тигез бүләргә ярдәм итүче һәм шул сәбәпле байлар белән ярлылар арасындагы аерманы бетерә баручы бердәнбер дин. Ислам, шулай итеп, кешене уңышка илтүче бәхет юлы булып тора.

Хәзерге вакытта 42 миллионнан артык кеше СПИДтан иза чигә. Бу сан исә - җәмгыятебездәге әхлакый кыйммәтләрнең бүгенге хәле нык булмаганлыкка дәлил. Технологияләр ягыннан алга киткәнбез, ә мораль яктан артта калганбыз. Ислам дине күңел кайтаргыч холык-фигыльләргә юл куймый торган кагыйдәләрне үз эченә ала. Исламда хатын-кызлар да, ир-атлар да гыйффәтле, тотнаклы булсыннар өчен җитди караш юнәлтелә. "(Ий, Мөхәммәд), мәэмин ирләргә әйт: (хәрамга) күз йомсыннар (күз атарга ярамаганнарга бакмасыннар, җенси вәсвәсәгә, азгынлыкка бирелмичә) пакьлекне сакларга кирәклеге турында сөйлә. Шулай эшләү аларның үзләре өчен әдәпле бер гамәл булыр. Шик юк ки, Аллаһ алар кылганнарның барысыннан да хәбәрдар. Мөәминә хатын-кызларга да сөйлә: (ярамаганнарга караудан) тыйлыксыннар; намус һәм гыйффәтләрен сакласыннар. Күрсәтергә яраганнардан (йөз белән куллардан) башка зиннәтләрен күрсәтмәсеннәр. Баш яулыклары, якалары муеннарын, күкрәкләрен каплап торсын. Зиннәт урыннарын үз ирләреннән, үз аталарыннан, үз ирләренең аталарыннан, үз угылларыннан, үз ирләренең (башка хатыныннан туган) угылларыннан, үз ир туганнарыннан, үз туганнарының угылларыннан, кыз кардәшләренең угылларыннан, үзенең (хезмәтче) асрауларыннан, үзләренең колларыннан, җенси ихтыяҗы булмаган ир хезмәтчеләрдән, хатыннарның яшерен җирләренә дикъкате булмаган балалардан башка кешеләргә хатын-кыз зиннәтле урыннарын күрсәтмәскә, ачмаска тиеш. Яшерелгән зиннәтләре беленсен, күренсен дип, (ирләрнең игътибарын тартырдай итеп) каты басмасыннар. Әй, мөәминәләр, барыгыз да Аллаһ алдында тәүбә итегез. Куркынычлардан котылып, морадыгызга (җәннәткә) ирешерсез" ("ән-Нур" сүрәсе, 30-31 нче аятьләр).

Кием киюебез - ул безне хайваннардан аерып торучы сыйфатларның берсе. Кешелек тарихының барлык чорларында да киеме була торып киенми йөрүчеләрне вәхшиләр (варварлар) һәм кыргыйлар дип атаганнар. Тән билгеләрен ачык белдертеп (ярымшәрә), оят урыннарны капламыйча йөрүдә хурланырлык нәрсә күрмәүчеләргә менә дигән заман җитте. Һәм бу ирекле булу дип атала! Бу рәвешле ирекле булганнарның берсенең дә банк счёты яки карточкасы номерын чыгарып салу башына килмәс дип ышанасы килә - бу ахмаклык. Ә ни өчен соң алайсам, тәнебезнең байлыгы турында сүз барганда, кеше шулкадәр ваемсызлык күрсәтә икән: бар матурлыгын тирәюньдәгеләргә ачып салып, теләсә нинди һөҗүмгә барырга әзер торучы ерткыч хайваннарны үчекләгән сыман, аларга хас сыйфатларны үзләштергән кебек кылана? Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Әй, Пәйгамбәр! Хатыннарыңа, кызларыңа һәм барча мөәминнәргә әйт, (йомыш белән урамга чыкканда) өс киемнәрен яхшылап капласыннар. Бу - (аларның затлы нәсел хатыны икәнен) танысыннар һәм рәнҗетмәсеннәр өчен бик тә кулай эш. Аллаһ - ярлыкаучы һәм миһербан иясе" ("әл-Әхзаб" сүрәсе, 59 нчы аять). "Әй, Адәм балалары, оят җирләрегезне каплар өчен кием, бизәкле күлмәкләр яралттык. Тәкъвалык (саф әхлак, диндарлык) - киемнәрнең иң гүзәледер. Болар Аллаһның галәмәтләредер. Бәлки яхшылап уйлый торгач, гыйбрәт алырсыз. Әй, Адәм балалары, ата-анагызны җәннәттән кудырыр өчен, шайтан аларның киемнәрен салдырып, оят җирләрен үзләренә күрсәтте; ул сезне дә шулай алдамасын. Чөнки ул (шайтан) һәм аның дуслары сезне күреп тора, сез аларны күрмисез. Хактыр ки, Без шайтаннарны имансызларның дусты иттек" ("әл-Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсе, 26-27 нче аятьләр). Җәмгыять, җенси азгынлык күренешләренә күнә барган тәртибебез (аеруча гаиләдә) белән, акрынлап җимерелә бара.

Расачылык, кеше фикере белән санашмаучанлык, кайсы да булса милләттән булуыңа карата чиктән тыш горурлык белдерү - кешелек тарихында күп кенә низагларның килеп тууына сәбәп булды. Ислам дине безне расачылык куркынычыннан азат итү өчен килгән бит, югыйсә. "Әй, адәм балалары! Хактыр ки, Без сезне бер ир, бер хатын итеп яралттык. Бер-берегез белән аралашыгыз дип, сезне кавемнәр вә кабиләләргә аердык. Хактыр ки, гөнаһ кылудан курыккан кеше Аллаһ каршысында иң олы абруй казаныр. Шөбһәсездер ки, Аллаһ барысын да белеп, барысыннан да хәбәрдар булып тора" ("әл-Хөҗүрәт" (Бүлмәләр) сүрәсе, 13 нче аять). "Аның күкләрне һәм Җирне юктан бар итүе дә, Ана телләрегезне, тән төсләрегезне төрле-төрле итеп яралтуы да - Аллаһның бәхәссез дәлилләредер. Хактыр ки, боларда хәбәрдарлар өчен гыйбрәтләр бар" ("әр-Рум" сүрәсе, 22 нче аять).

Безгә Аллаһ тарафыннан бирелгән Ислам - ул җәмгыятебезне яманлыклардан арындырырга сәләтле яшәү рәвеше. Мөселманнар бар нәрсәдә, бигрәк тә гыйбадәттә бердәм. Хаҗ кылганда, шул исәптән король һәм президент та, - бөтен кеше дә ихрамнан йөрергә тиеш. Ислам - ул гамәл вә гыйбадәт дине. Күрекле мөселман булыр өчен, гел хезмәт итәргә, шул исәптән, үз-үзеңә тырышлыклар куярга, контрольне көчәйтергә, гыйбадәткә һәм дисциплинага буйсыну өчен әзер торырга кирәк. Ислам дине мөселманнардан чыдам булуны сорый: күңелне аздыра торган нәрсәләргә каршы торырга үзеңдә көч булдыру һәм ашау өчен генә яшәмәс өчен ихтыяр көчен үстерү таләп ителә - шул максатны тормышка ашыру ниятеннән без ураза тотарга тиешбез. Динебез кушканча яшәү иге-чиге күренмәгән белемнәргә омтылыштан башка була алмый. Коръәндә әйтелгән: "Кешеләр арасында да, хайваннар, мал-туар арасында да шундый төстәгеләре бар. Галим кеше Аллаһның җәзасыннан курка (чөнки ул - укыган, белемле. Надан кеше генә Аллаһны бар дип тә белми). Шик юк ки, Аллаһ һәрвакыт өстен, чиксез ярлыкаучы" ("Фатыр (Яралтучы)" сүрәсе, 28 нче аять). "Сабыр-чыдам булганнар, иманнарына тугры калганнар, гыйбадәттә итагатьле булганнар, хәер биргәннәр: "Йа Раббыбыз, без иман китердек. Инде безнең гөнаһларыбызны кичер вә безне җәһәннәм газапларыннан коткар! - дип сәхәрләрдә Аллаһтан ярлыкау сорарлар" ("әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)" сүрәсе, 16-17 нче аятьләр); "(Мөселманнар) каушамагыз, хафаланмагыз, әгәр дә сез мөәмин-мөселман икәнсез, сез барчасыннан өстен булырсыз" ("әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе) сүрәсе", 139 нчы аять).

Югарыда язылганнар Исламның кайбер өстенлекләрен күрсәтү һәм ул җәмгыятебезгә нинди үзгәрешләр алып килергә мөмкин икәнлеген белгертү булып тора. Әмма бер генә мәкаләдә ачып бирергә мөмкин булмаган башка күп кенә сораулар да бар. Нәкъ менә шуңа күрә ислам динен тагын да тирәнрәк, эзлеклерәк һәм җентеклерәк тикшерергә кирәк. Исегездә тотыгыз: Ислам - ул эшхәрәкәт, тәртип, аң-белем, батырлык, тәвәккәллек һәм сабырлык дине... Хөрмәтле укучым, сез чыннан да тырышмы? Сез җитәрлек дәрәҗәдә дисциплиналымы? Сез шактый акыллы? Кыюлыгыгыз, түземлегегез, көчегез җитәрлекме? Башка сүзләр белән әйткәндә... сез Исламга әзерме?

Руслан хәзрәт МОРТАЗИН,
Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые

(Дәвамы. Башы газетабызның 5, 6 нчы саннарында.)

- Бик шәп булыр, күтәрелсә! Чүплеккә әзрәк ташлар! - дип кискен кире кага аның сүзен Бибинур. Былтыр улы янына Казанга баргач, өй янындагы чүп тартмаларына икмәк кисәкләре, хәтта яртышар батон ыргытылганын күргәннән соң, шактый исе китеп, тетрәнеп кайтып киткән иде ул авылга.

Айдар кебек яшьләр моны бик үк аңлап бетермәсәләр дә, өлкән буын кешеләре ипи кадерен яхшы белә, аңа кытлык булган вакытларны онытмый.

Бүгенге җәмгыять кешеләре өчен зур байлыкка ирешү бәхет саналса, өлкән буын вәкилләре өчен заманында бер кисәк ипи зур бәхет булган.

Ул арада Гарәфетдин бабай хатирәләрен яңартып, ашыкмыйча, ипләп кенә сөйли башлый:

КАПКА ТӨБЕНДӘ

(бәян-вәгазь)

- Ие шул... Сугышның, ачлыкның нәрсә икәнен белгән өлкәннәр икмәкне бик хөрмәтли, кадерли... Аллаһы Тәгалә бит һәр буынны Үзе теләгәнчә сыный. Без яшь чакта, совет чорында Алласызлык сәясәте, динсезлек афәте зур сынау булды. Соңгы 2 дистә елда халыкка дин юлына басарга, гыйбадәт кылып яшәргә бөтен мөмкинлекләр бирелде. Тормыш ничек әйбәтләнде бит хәзер, ә? Ул әфлисун-мәндәринне без элек төшебездә дә күрмәдек. Хәзерге уңайлыклар турында хыялланмадык та. Ә халык нишли? Шөкер итәсе, Аллаһы Тәгалә кушканча яшисе урынга нәфесләнеп байлык артыннан куа, ришвәт бирә-бирә балаларын укырга кертә, бар эшен акчага тәвәккәлли... Яше-карты хәмер белән дуслашты, бозыклыкка чумды. Илебездә үзгәртеп кору, кем әйтмешли, пириструйка башланганнан соң, динебезгә ирек бирелгәннән соң 25 ел узды. Чирек гасыр көтте Аллаһы Тәгалә! Хәзер инде менә бәрәкәтен киметеп, быел Үзенең бер нигъмәтеннән - яңгырдан мәхрүм итте...

Нәрсәдер исенә төшергәндәй, бабай бер мәлгә тынып кала. Янында булучылар, хәтта Мәрфуга апа да, аны бүләргә кыймыйча, тынлыкны саклап, кымшанмыйча утыра. Гарәфетдин абый исә балачакта кычыткан ашын, чергән бәрәңге уалмасын ашаганнарын һәм шул вакытта да авылда яшәүчеләрнең күбесе намазда булуын исенә төшерә. Хәмер эчүчеләр дә юк иде диярлек. Һәр гаиләдә 6-7 шәр бала булуга карамастан, халык ничектер бик юмарт, киң күңелле иде, тормыш бәрәкәтле булды шикелле. Ә бәлки, шулай тоелгандыр? Канәгать булганга, барның кадерен белгәнгә Аллаһы Тәгалә күңелләргә тынычлык салгандыр. Ә хәзер бит кеше булганына риза түгел, һаман әзсенә, һаман нәфесләнә. Байлыгымны арттырам, күбрәк акча эшлим дип күпме көчәнсә, шул кадәр күңел тынычлыгын югалта, төшенкелеккә бирелә. Ә ни өчен шулай? Бу сорауга җавапны бабай төгәл белә, шуны авылдашларына җиткерергә теләп, сүзен салмак кына дәвам итә:

- Ие шул... Ие... Бүген байлыкка, бәхетле, мул тормышка омтылучы халыкның төп ялгышы - Аллаһ ризалыгы дигән нәрсәне онытып, бәхетне акчада эзләве. Ә бәхет асылы бит аңарда түгел. Аллаһы Тәгалә бер үк дөнья нигъмәтен кемгәдер шатлык-сөенеч итеп бирергә мөмкин, ә кемгәдер көенеч, кайгы-хәсрәт итеп. Исегездәме, былтыр Рәниф тә машина алды, Илнур да. Илнур бүгенгәчә машинасына утырып эшенә дә йөри, хуҗалыкта, гаиләсе өчен дә аннан файдалана, ә Рәниф авариягә юлыгып, хәзер инде елдан артык урын өстендә ята. Әнә Хәйретдиннәр, кызлары укырга керде дип ничек шатланганнар иде, ә ул бала өенә мәет булып кайтты. Кечкенәрәк мисал да китерә алам. Гаптериләр бая карбыз ашап нишләде? Агуландымы? Ие. Югыйсә бит авыл кибетенә кайткан шул ук карбызны башка кешеләр дә ашады. Без дә бик яратып авыз иттек. Ә Гаптеригә менә нәрсә булды. Уйланырлык нәрсә бар, җәмәгать...

Озын сүзнең кыскасы - кемгәдер малмөлкәт, дәрәҗә бирелсә, шатлыкмы бу аның өчен, әллә хәсрәтме - төгәл билгеле түгел. Барлык хикмәт Аллаһның теләгендә. Бәрәкәт тә Аның карамагында. Өебезгә, тормышыбызга бәрәкәт килсен дисәң, иң элек бит Аллаһ ризалыгын алырга тырышырга кирәк. Ә бездә ничек? Халык Аллаһның ачуын китерә торган гамәлләр эшләп яши, ә үзе бәхетле булырга тели. Ә алай була аламы соң ул, ә?!

...Шулай сөйли-сөйли бераз кызып киткән Гарәфетдин бабайның авызына карап, аның һәр сүзен "йотып" баручы Мәрфуга апа бу урында сабырлыгын жуеп кинәт каты нечкә тавышы белән әйтеп куя:

- Шушы гөнаһ кылып яши торган халыкка Аллаһы Тәгалә ничек түзәдер, әстәгъфируллаһ!

Җайлы-көйле генә бара торган вәгазьне бүлгән Мәрфуга апаның кычкыруына капка янындагылар башта сискәнеп куя, аннары, ачулары кабарып, шелтә белдерәбез дигәндә генә Гарәфетдин бабай янә сөйләп китә:

- Ие, кеше бит, гадәттә, авырлыкка чыдый, ә рәхәткә, нигәдер, түзә алмый. Авырлыкта халык ничектер чыныга, күбрәк дога кыла, сорый, ялвара, ә рәхәтлектә - бозыла, аза башлый. Җир йөзендә рухи пычраклык, кабәхәтлек күбәйсә, Аллаһы Тәгалә кешеләргә берәр авырлык биреп, уйланырга, тәүбәгә килергә мөмкинлек ача. Быелгы корылык та, ярма, бәрәңгенең бәяләре кинәт күтәрелү дә Аллаһ Раббыбызның соңгы 25 елда безгә ясаган беренче житди кисәтүедер! Башка илләрдә бит, ишетеп беләбез, йә жир тетри, йә су баса, йә кан түгелә. Бездә моңарчы, Аллага шөкер, әле бик тыныч булды, ләкин бит халык аңларга тиеш: гел шулай Аллаһы Тәгаләнең ачуын китереп яшәсәң, Аның газабы төшүе дә бик ихтимал...

Капка төбендә булучыларга ошамаячагын белсә дә, Мәрфуга апа янә түзми һәм бабайны бүлдереп, һәркем аңларлык - ишетерлек булсын диптер инде, әйтәсе килгән сүзен кычкырып, ижекләп ярып сала:

- Бик хак, дө-рес әйт-тең син, Га-рә-фи! Лә-кин бу бо-зыл-ган, а-зып бет-кән та-тар-лар-ны бү-ген ачлык бе-лән ге-нә жи-ңеп бу-ла-а!!!

Бермәлгә телсез-өнсез калган капка төбендәгеләр ачулы йөзләрен карчыкка борып, шаккатып текәлә. Ачуыннан бүртенгән Бибинур түтинең кашлары борынына кадәр төшкән. Күзлегенең калын пыяласы аша бермә-бер зуррак күренгән әлеге кашлар илә Мәрфуга өстенә хәзер нинди дәһшәтле, явыз көч ябырылачагын чамалап була иде. Түти инде авыр сулап мышный да башлады, әмма... авыл мәчете манарасыннан, ахшам намазының вакыты керүен белдереп, азан яңгырады. Нинди йомшак, күркәм, тыныч тавыш! Авыл өстенә тарала башлаган шушы азанның уңай йогынтысы нәтиҗәсендә әле генә туган киеренкелек басылды, бар кешеләр жиңел сулап куйды, хәтта түтинең кашлары да кире урынына кайтты.

Шулай сүзсез-нисез азан тыңлап бетергәннән соң, кул күтәреп дога кылдылар. Гарәфетдин бабай, ахшамны мәчеттә укырга ниятләп, яндагы ирләргә дә шунда керергә тәкъдим итте:

- Әйдәгез әле бер саваплы гамәл кылыйк, булмаса: мәчеткә кереп намаз укып чыгыйк!

- Минем бабай заманында мулла булды! Беләсезме шуны? Би-ик гыйлем кеше иде! - дип җаваплады Илгиз абый.

Мәхсүт абый исә: "Мин әле пенсиягә чыкмаган! Менә пенсиягә чыгуга укый башлармын!" - диде дә, горур кыяфәт белән торып өенә таба атлады.

Матур челтәрле, йомшак паласлы, пөхтә, жыйнак, ямьле гыйбадәтханәдә бабай белән Айдарны бераз шомлы тоелган тынлык каршы алды. Мәчет имамы, 73 яшьлек Кәримулла хәзрәт белән өчәүләп ахшам намазын укыдылар. Хәзрәт инде олы яшьтә булса да, моңарчы имамлык эшен башкарып килде, чөнки 140 хуҗалыклы авылда имам булырга түгел, мәчеткә кереп намаз укып кына чыгарга да теләүчеләр юк иде.

(Дәвамы газетабызның киләсе саннарында.)

Ришат КУРАМШИН,
Кукмара мәдрәсәсе мөдире

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНДА АЗАТЛЫК ӨЧЕН КӨРӘШ СӘХИФӘЛӘРЕ

Мәчетләр җимертү хакында

Коллыкка эләккән халыкның язмышы гасырлар дәвамында яшәү өчен көрәш юлыннан бара. Казан алынганнан соң күргән авырлыклар артыннан дини һәм башка юнәлештәге эзәрлекләүләрнең яңа этабы башлана. Бу милли кысуларны XVII гасыр ахырыннан император Пётр I янә дә башлап жибәреп, жәберләү 1775 елга кадәр дәвам итә.

Дини эзәрлекләүләр темасы тарихыбызда бик нык тикшерелмәсә дә, бу хактагы мәгълүматлар галимнәрнең хезмәтләрендә дөнья күрә тора.

Татар тарихчыларыннан Фәйзелхак Ислаевның бай чыганакларга таянып язылган китаплары, Ефимий Малов көндәлекләренең татар һәм рус телләрендәге басмалары әлеге җәһәттән дини-милли изүнең бөтен чынбарлыктагы барышын һәм вәхшилеген ачып бирәләр.

Әлбәттә, бу вакыйгаларның шаһитләре булып күп саны архив документлары калган, XIX-XX гасырларда исә халык иҗаты материалларын да беләбез. Мәсәлән, "Зөлхәбирә", "Елыш бәете", "Мостафа мулла", "Хәерниса" кебек бәетләр мәгълүм. Күпсандагы риваять-легендалар да бар. Ә менә инде XVIII гасыр хәлләренә килгәндә, бу дәвердән халык иҗаты үрнәкләре дә, әдәби ядкарьләр дә сан ягыннан бик чикле хисаплана. Әлбәттә, күп кенә татар кулъязмалары битләрендә дини эзәрлекләүләр турында да хәбәрләр бардыр, ләкин әлегә аларны өйрәнүчеләр күренми.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсендә саклануче борынгы язма китапларның берсендә узган дәверләрдә мәчетләр җимерү вакыйгасына багышланган бер мөнәҗәт саклана. Әлеге кулъязма китапның күчерелү вакыты 1769 ел дип күрсәтелә. Аны мирасханәгә Бөгелмә шәһәреннән табып тапшыргаллар.

Шигырь-мөнәҗәтнең теле гарәп-фарсы алынмалары белән нык баетылган, бу үзенчәлек текстны аңлауны кыенлаштыра. Әлеге поэтик әсәр бары утыз юлдан гыйбарәт, начар сакланышлы кәгазьгә гарәп хәрефләре белән саксыз рәвештә күчерелгән, уку өчен үтә кыен.

Текст белән танышкач, анда һижри 1155 елда, милади 1742 елда миссионер Лука Канашевич һәм аңа ярдәмгә бирелгән рус солдатлары кулы белән мәчетләр җимерттерү тарихы бәян ителгәнлеге аңлашыла.

Әлеге тарихи вакыйга турында моңа кадәр табылган татар кулъязма хроникаларында искә алынган кыска сүзләр барлыгын беләбез: "1155 - мәсҗетләр бозылды, эт елы иде".

Архивта сакланган, югарыда искә алынган шигырьнең татар әдәбияты тарихы өчен әһәмияте кечкенә түгел. Ул аңа яңа тема алып керә, шуның белән әдәбиятыбыз тематикасының дөньяви юнәлешенә яңалык өсти.

XVIII гасыр татар язма поэзиясендә Габди һәм Габдессәламнәр әсәрләрендә күренгән реаль тормыш картиналары, бу шигырьдә милли-дини изү темасы белән баетылган.

Мәчетләр җимерүгә каршы йөрүчеләр

Мәчетләр жимерү темасына багышланган янә бер поэтик әсәр 2002 елның җәендә табылды. Ул - кабер ташына язылган унтугыз юллык мәрсиядән гыйбарәт. Ташны 1756 елны 41 яшендә үтерелгән Биккол Ибраһим улы истәлегенә Өлә Казаклары авылы зиратына куйганнар. Гүзәл каллиграфик стиль белән язылган эпитафия тексты әдәбиятыбыз һәм халкыбыз тарихына кызыклы сәхифәләр өсти. Аны каллиграф Исхак Габделкәрим улы ташка уеп калдырган. Текст калкытып сөлес стилендәге гарәп язуында эшләнгән.

Мәрсиядә Биккол бине Ибраһимның "мәсҗедләр" жимерелгән вакытта, авылларга барып хәлләрне тикшереп йөрүе һәм мөселманнар хәсрәте белән рус императорының хозурына барулары, анда халык исеменнән динне, мәчетләрне хурлауның нигезсезлеген падиша колагына кыюлык белән житкерүе тасвирлана. Мәрсия авторы Өлә (өйлә) авылы ирләренең матур, куркусыз холыклы булуларын мактый.

Үзенең дуслары ярдәме белән Биккол бине Ибраһимның Оренбургтагы дошманның гайрәтен бетерде дигәнне Оренбургтагы мөселманнарны кыздыручы губернатор Иван Неплюевның 1744-1758 елларда-гы идарәсе вакытындагы законсыз эшләренә каршы чыгуы дип аңларга мөмкин. Бу вакыйгалар тарихчылар тарафыннан өйрәнелергә лаеклы.

Мәрсия багышланган Биккол бине Ибраһим үз дәверендәге галимнәр, атаклы кешеләр белән таныш булган. Яхшы эшләре белән, легендар гашыйк Таһир-Зөһрәгә мәхәббәте белән ничек танылса, ул да шулай халыкта шөһрәт казанган дип язылган. Ташта Бикколның атасының исеме Ибраһим-Әдһәм икәне дә ачыла.

Татар әдәбияты тарихында әлегәчә мәрсия жанрының фәкать XVIII гасыр ахырында Габдерәхим Утыз-Имәни иҗатында гына булуы мәгълүм иде. "Мәрсия-и Биккол бине Ибраһим" әсәре жанрның татар поэзиясендәге башлангычын - әлегә XVIII гасыр уртасына күчерде. Аның теле хәйран гына катлаулы булса да, шигъриятебездәге реализм күренешләрен, әдәбиятыбыздагы "Таһир-Зөһрә" сюжетының халыкта нык танылуын күрсәтү ягыннан тарихи чыганак буларак та әһәмияте зур күренеш.

Әлеге Биккол бине Ибраһим эпитафик истәлеге янында шул ук таш кисүче тарафыннан Бикколның атасы Ибраһим бине Әлкәй һижри буенча 1175, миладича исәп белән 1761/62 елда үлгәч куелган таш сакланган. Ташның зурлык-габаритлары алда язылганнан аерылмый диярлек. Шулай ук гарәп язуының сөлес стилендә калкытып язылган 13 юллык текст сакланган.

Эпитафик текстның башында зур итеп "Мәрсия-и Ибраһим бине Әлкәй" дип исем куелган. Кабер ташы әүвәлдә кызыл кирпечтән эшләнгән дөрбәнең тышкы ягында булып, дөрбә стенасы хәзер жимерелеп бетә язган.

Ибраһим бине Әлкәй үзе исән чагында Өлә Казаклары авылында мәдрәсә тоткан булган. ТР Милли музеенда саклануче Зәйнәп Максудова фондында аның мәдрәсәсендә 1182/1768 елда Баттал бине Журта исемле шәкерт тарафыннан күчерелгән, шәригать гыйлеменә караган, 206 битле "Мөхтасарел-вәкая" исемле кулъязма китап та саклана. Бу фактта шундый мәгълүматлар алырга мөмкин: "Болгар вилаяте, Казаклар аулында" Ибраһим бине Әлкәй исемле мөдәррис мәдрәсәсе булып, ул 1761 елны үлгәч тә "мелла Ибраһим мәдрәсәсе" исеме белән эшләвен 1768/69 елларда да дәвам иткән.

Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы, профессор

Өлкәннәр өчен бәйрәм

21 август көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге хезмәткәрләре Югары Ослан районындагы Инвалидлар һәм өлкәннәр интернат-йортында булып кайтты.

Интернатта яшәүчеләр өчен профессиональ артистлар тарафыннан махсус концерт программасы әзерләнгән иде.

Ураза гаетенә багышланган төп чарадан соң, олылар өчен подгузниклар һәм урынжир кирәк-яраклары таратылды.

Әлеге бәйрәм чарасы башкалабызда эшчәнлек алып баручы яшь эшмәкәрләрнең иганә акчасына оештырылды.

ИРЕМНЕҢ ИКЕНЧЕ ХАТЫНЫ БАРЛЫГЫН БЕЛДЕМ...

Ирем белән гаилә корып яши башлаганыбызга өч ел булды. Эш урыны башка шәһәрдә булу сәбәпле, ул күбесенчә шунда яши. Безнең кызыбыз үсеп килә, ирем - бик яхшы кеше, мин аннан башка яши алмыйм. Көннәрдән бер көнне ул миңа тагын бер гаиләсе - хатыны һәм улы булуы турында белгертте. Иремнең аларны ташлап китә алмавын аңлыйм, ләкин көнчелегем аркасында үземне күлда тота алмыйм бит. Ирем исә мине яратуын, шул ук вакытта икенче хатынын да ташлап китә алмавы турында әйтә. Кайчак миңа шулкадәр кыен була ки, мин ирем белән аерылышырга кирәк дигән нәтиҗәгә киләм. Тик ул минем белән дә, аның белән дә балалар үстерү турында хыяллана. Мин нишләргә дә, кая барып бәрелергә дә белмим, чөнки иремне үлеп яратам! Зинһар, киңәш бирегез миңа.

М., Зәй шәһәре

Сезнең соравыгызга Татарстанның көнчыгыш төбәге казые, Әлмәт районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов җавап бирә:

- Ислам дине ир кешегә берничә хатын белән никахлашуны тыймый. Коръәни-Кәримдә болай диелгән (мәгънәсе): "Әгәр аларга (ятимәләргә) гадел булмаудан курыксагыз, үзегезгә ошаган хәләл хатыннарга өйләнегез: икесенә, өчесенә, дүртесенә (никахлаша аласыз). Әгәр гаделлек кыла алмаудан курыксагыз, берсен генә алыгыз, алай да булмаса, сезгә сатып алган кәнизәкләрегез җитәр. Бу - Аллаһ юлыннан тайпылмас өчен, гаделсез булмас өчен кулайдыр" ("ән-Ниса (Хатыннар)" сүрәсе, 3 нче аять).

Көнләшү - хатын-кызларга хас хис ул. Ләкин көнләшүегезне таләп, үпкә, низаг белән белдермәгез, чөнки алар барысы да гөнаһ санала һәм ул адәм баласын тагын да зуррак гөнаһларга алып керергә мөмкин. Бу рәвешле ризасызлык белдереп (хатын-кыз иренә каршы төшүдән бигрәк), ир-атка берничә хатын-кыз белән никахлашырга рөхсәт иткән Аллаһы Тәгалә Сүзенә каршы килүегез бар.

Бик күпләр: "Ир-ат икенче хатынны беренче хатыны канәгатьләндермәсә ала", - дип әйтә. Ләкин дөреслектә бу алай түгел. Икенче никах өчен сәбәпләр күп булырга мөмкин. Мәсәлән, башка хатын-кызга ярдәм кулы сузарга теләү, аңа тормышта ир хатыны, ана булу бәхетен бүләк итү. Шуңа күрә беркайчан да ирегез икенче хатынын сездән риза булмаганга алган дип уйлый күрмәгез. Көнләшү хисегезне башкаларга белдермәс өчен, сезгә иң әүвәл ирегезнең ризалыгын кабул итәргә кирәк. Сез ирегезнең яхшы кеше булуын, аның сезне яратуы турында язасыз. Ә никадәр хатын-кыз, ирләренең бердәнбер хатыннары булуына да карамастан, сөйгәннәре турында андый сүзләр яза алмый.

Сезгә шундый яхшы ир насыйп иткәне өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер итегез. Кабатлап әйтәм: Аллаһы Тәгаләгә буйсынмаган өчен ахирәттә җәза каралган кебек, Аңа итагать итсәк, моның өчен әҗер-савабыбызны да арттырырбыз. Кыенлыкларны күбрәк күргән саен (шул исәптән рухи яктан да) түземлелек һәм итагатьлелек күрсәтүегез бәрабәренә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешерсез. Коръәни-Кәримдә, мөселманнарның кечкенә генә игелек эшләгәннәре өчен дә әҗер-савап алачагы турында әйтелгән.

Бик күп хатын-кызлар, аерылу өчен шәргый сәбәпләр була торып та, Аллаһ хакы, бала хакы өчен дип ирләреннән аерылмыйлар, һәм бу дөрес тә. Чөнки бездә балалар, ата-анасы аерылганнан соң, исән килеш ятим хөкемендә калалар, балачаклары бәхетсез була. Ә бит балалар хакы турында Кыямәт көнендә ата-анадан соралачак! Ирегез дә сезгә белгертмичә икенче хатынга никахланып хата ясаган һәм ул хатасы өчен сездән гафу үтенергә тиеш. Сезнең төннәрне тигез бүләргә хакыгыз бар: әмма ирегез сездән икенче никахын яшергән һәм сезне хокукыгыздан мәхрүм иткән. Яшерен рәвештә никах уку шәригатебезгә каршы килә.

Никахыгыз котлы булсын!

Мамадыш шәһәрендәге Әхмәт Ясәви мәчете имам-хатыйбы НУРИСЛАМ НУРЕТДИН улы ГАЗИЗОВ белән ЛӘЙСӘН ФАЗЫЛ кызы ЛАТЫЙПОВАның *24* августта никахлашу көне.

Без сезне олы тормыш юлына басуыгыз - никахлашу көнегез белән кайнар тәбриклибез! Тормыш тәҗрибәсе зур булган өлкәннәрдән үрнәк алып, сау-сәламәт балалар үстереп, аларның игелеген күреп, әти-әниләрегез, туганнарыгыз сөенерлек, ислам динен куәтләп, изге гамәлләр генә кылып, куанычлы хәбәрләр генә ирештереп, бергә-бергә бәхетле гомер көзегезне тигезлектә каршы алырга Аллаһы Тәгалә насыйп итсә иде.

Хәерле юл Сезгә, яшәгез гел
Сандугачлар кебек сайрашып!
Алтын туегызның түрендә дә
Утырыгыз шулай парлашып.

Онытмагыз, сәгать санап тора
Бу елларның үтеп барганын.
Югалтмагыз, соңгы көзгә кадәр
Мәхәббәтнең алтын балдагын.

Иң изге теләкләр белән, Мамадыш мөхтәсибәтеннән ИЛҺАМ хәзрәт МИҢНЕГАЛИЕВ һәм Мамадыш шәһәреннән МИНГАЛИЕВлар гаиләсе.

Казанда намаз вакытлары

Көн исеме	Дата	Иртәнге намаз	Кояш чыгу	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
Шимбә	25.08.12	4:05	5:35	13:02	17:37	19:55	21:25
Якшәмбе	26.08.12	4:07	5:37	13:02	17:35	19:52	21:22
Дүшәмбе	27.08.12	4:09	5:39	13:02	17:34	19:50	21:20
Сишәмбе	28.08.12	4:11	5:41	13:02	17:32	19:47	21:17
Чәршәмбе	29.08.12	4:13	5:43	13:02	17:31	19:45	21:15
Пәнҗешәмбе	30.08.12	4:15	5:45	13:02	17:29	19:42	21:12
Җомга	31.08.12	4:17	5:47	13:02	17:27	19:40	21:10
Шимбә	1.09.12	4:19	5:49	13:02	17:25	19:37	21:07

Чаллы шәһәренең *"АК МӘЧЕТ"* мәдрәсәсе УКЫРГА ЧАКЫРА

"Ак мәчет" мөселман мәдрәсәсе яңа уку елына укырга теләүчеләрдән гаризалар кабул итә.

Мәдрәсә ТР Мәгариф министрлыгының лицензиясе нигезендә (серия А № 297993) имам-хатыйблар, башлангыч дини белем бирү укытучылары әзерли. Мәдрәсәдә Мәдинә Ислам университеты, Каһирәдәге Әл-Әзһар университеты кебек дәрәҗәле дини уку йортларында белем алган, югары дини һәм дөньяви белемгә ия мөгаллимнәр укыта. Бездә көндезге, кичке һәм читтән торып уку бүлекләре эшли.

КӨНДЕЗГЕ БҮЛЕК. Мәдрәсәгә IX-XI класс белемгә ия 25 яшькә кадәрге егетләр кабул ителә. IX-X сыйныфны тәмамлап килүчеләр урта мәктәптә укып дәүләт аттестаты алу мөмкинлегенә ия. Уку вакыты - 3 ел. Дәресләр 1 сентябрьдән башлана.

КИЧКЕ БҮЛЕК. Мәдрәсәгә төрле яшьтәге ир-атлар һәм хатын-кызлар кабул ителә. Ир-атлар дүшәмбе һәм чәршәмбе көннәрне кичке сәгать алтыдан (18.00) тугызга (21.00) кадәр, хатын-кызлар шимбә, якшәмбе көннәрендә көндезге сәгать уникедән (12.00) дүртенче яртыга (15.30) кадәр укый. Уку вакыты - 3 ел. Дәресләр 1 октябрьдән башлана.

ЧИТТӘН ТОРЫП УКУ БҮЛЕГЕ. Мәдрәсәгә төрле яшьтәге ир-атлар һәм хатын-кызлар кабул ителә. Кышкы сессия: ир-атлар өчен 20 декабрьдән 31 декабрьгә, хатын-кызлар өчен 1 гыйнвардан 10 гыйнварга кадәр. Җәйге сессия: ир-атлар өчен 20 майдан 31 майга, хатын-кызлар өчен 1 июньнән 10 июньгә кадәр. Уку вакыты - 3,5 ел.

Мәдрәсәдә уку һәм яшәү өчен барлык шартлар тудырылган: тиешле таләпләргә туры китереп җиһазландырылган уку класслары, ашханә, спортзал, китапханә, юыну бүлмәләре, намаз уку залы һәм тулай торак - болар барысы да бер бинада. Укучыларны көненә өч тапкыр ашату, кич белән ял итү, спорт уеннары, төрле кичәләр, конкурслар, табигатькә чыгып ял итүләр оештырыла.

Укырга килүчеләргә түбәндәге документлар белән килү шарт:

1) ректор исеменә гариза (балигъ булмаганнарга ата-аналары исеменнән дә);
2) паспорт (оригинал һәм ксерокопия);
3) урта белем (яисә IX, X класс белем) турында аттестат;
4) фотосурәт (3х4 см), 4 данә;
5) медицина белешмәсе (086 У формасы);
6) хезмәт кенәгәсе (мәктәпне тәмамлаганнан соң эшләүчеләр өчен).

Шул ук вакытта, дини гыйлеме булмаганнар, әмма динебезне тотарга теләгәннәр өчен "Ак мәчет" мәдрәсәсе каршында атналык курслар оештырылуы хакында да хәбәр итәбез. Бу курсларда ислам дине нигезләре, намаз, Коръән уку тәртипләре өйрәтеләчәк. Дәресләрне мең еллык дини традицияләребезгә таянып, үзебезнең мәдрәсә мөгаллимнәре бирәчәк. Укырга теләүчеләр милләттәшләребез яшәгән барлык төбәкләрдән дә кабул ителә (тик алдан хәбәр итүләре сорала). Укучылар бер авылдан яисә бер төбәктән бергә тупланып килсәләр безнең өчен уңайлы булыр иде.

Укырга килүчеләр үзләре белән 1500 сум күләмендә акча (яшәү, көненә өч тапкыр туклану шул суммага керә), гигиена әйберләре, мендәр тышы, простыня, язу кирәк-яраклары алып килергә тиеш.

Белешмәләр өчен телефоннар: +7 (8552) 38-67-02 (кабул итү бүлмәсе), +7 (8552) 38-86-33 (вахта).

Безнең адрес: 423810 Яр Чаллы шәһәре, Энтузиастлар бульвары, 12 нче йорт (Яңа шәһәр, 2/14 йорт).

МӘДРӘСӘ САЙТЫ: WWW.AKMECHET.RU.

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 8 (151) чыгарылыш.
Гамәлгә куючы һәм нәшир: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
Баш мөхәррир: Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
Мөхәррир: Нияз САБИРҖАНОВ.
Дизайнер: Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
Тираж: 5000 данә. **Заказ:** 9413.

Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.
Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
График буенча бу санга 23 август көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.
Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.
Электрон адрес: niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!